| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.05.2016 № 261

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 2 июнендә теркәлде, № 3376

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
"Гражданнарга кулай эш эзләүдә,
ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда
булышу дәүләт хезмәтен күрсәтүнең
административ регламентын раслау хакында"
17.06.2015 ел, № 419 боерыгына үзгәрешләр кертү турында

**Боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Гражданнарга кулай эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышу дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында" 17.06.2015 ел, № 419 боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Административ регламентның гражданнарга кулай эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышу дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гаризаны дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерактагы эш урыннары аша бирү өлешендәге пунктлары КФҮ һәм Татарстан Республикасының мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре арасында килешү имзаланганнан соң көченә

керә.”;

Гражданнарга кулай эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышу дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Боерык белән расланган административ регламентында (алга таба – Административ регламент):

1.8 пунктта:

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 31 июлендәге “Медицина-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениеләре тарафыннан бирелүче, инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын төзү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында” № 528н боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 24 август, басылып чыгу номеры: 0001201508240045);”;

унҗиденче абзацны төшереп калдырырга;

унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) [20];”;

20 нче сносканы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“[20] Алга таба – 02.11.2010 ел, № 880 ТР МК карары белән расланган Тәртип”;

Таблицаның 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып; туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | Халык мәшгульлеге үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (гражданинга, эш бирүчегә) дәүләт хезмәте күрсәтүнең рөхсәт ителгән максималь вакыты 20 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Гариза бирүче (гражданин, эш бирүче) кабат мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтүнең рөхсәт ителгән максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылмаган”; | № 524н Федераль стандартның 17, 23 п. п.;<br>№ 524н Федераль стандартның 18, 24 п. п.”; |

Таблицаның 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый | 1. Халык мәшгульлеге үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (гражданинга) дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар булып, түбәндәгеләр тора:<br>- гражданинның кулай эш эзләүдә булышу дәүләт хезмәтен күрсәтү | № 524н Федераль стандартның 5, 13 п. п.;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 07.09.2012 ел, |

| | | |
|---|---|---|
| актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | турында 26.02.2015 ел, № 125н Боерык белән расланган форма буенча гаризасы;<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен (гражданлыгын) таныклаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- шәхесне таныклаучы документлар (гражданлыксыз затлар өчен);<br>- инвалидны тернәкләндерүнең билгеләнгән тәртиптә бирелгән һәм хезмәтнең киңәш ителүче рәвеше һәм шартлары турында бәяләмәне үз эченә алучы индивидуаль программасы[21] (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен). | № 891 карары белән расланган Гражданнарны кулай эш эзләү максатыннан теркәү кагыйдәләренең 3 п.; |
| | Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче (гражданин) документлар күрсәтә ала, шул исәптән түбәндәгеләрне:<br>- хезмәт кенәгәсе яки аны алыштыручы документ, шулай ук хезмәт килешүләре һәм хезмәт | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 07.09.2012 ел, № 891 карары белән расланган Гражданнарны |

| | | |
|---|---|---|
| | итү контрактлары;<br>- һөнәри квалификацияне таныклаучы документлар, шул исәптән гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турындагы документлар, укыту узуга бәйле – мәгариф эшчәнлеге белән шөгыльләнүче оешмалар тарафыннан бирелүче документлар һәм белем турындагы документлар;<br>- соңгы өч айдагы уртача хезмәт хакы турында соңгы эш урыныннан белешмә;<br>- гражданинның хезмәт яки башка эшчәнлеген Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә туктатуын раслаучы документлар (гражданлык-хокукый рәвештәге килешү, шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекне туктату турында документ, нотариус вәкаләтләрен туктату турында документ, адвокат статусын туктату турында документ);<br>- гражданинны кулай эш эзләүдә кыенлыклар кичерүчеләрнең Халык мәшгульлеге турындагы | кулай эш эзләү максатыннан теркәү кагыйдәләренең 4 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| | законның 5 статьясы белән күздә тотылган категориясенә кертүне раслаучы документлар (инвалидлык төркемен күрсәтеп, инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә; ирektән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителү турында белешмә; Россия ФМС органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелгән, гражданинны качак яки мәҗбүри күченеп килүче дип тануны раслаучы документ; Чернобыльдәге һәм башка радиацион аварияләр һәм һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданин таныклыгы; хәрби билет, азат итүнең нигезен күрсәтеп, хәрби хезмәттән азат итү турындагы боерыктан өземтә, никах таныклыгы, хәрби частьтан белешмә; баланың туу турындагы таныклыгы, никахны өзү турында таныклык, ире (хатыны) үлү турында таныклык, балага инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә, күпбалалы гаилә таныклыгы, гражданинның | |

| | | |
|---|---|---|
| | бердәнбер ата (ана) булуын раслаучы документ, һәм шулай ук балигъ булмаган балаларны, инвалид балаларны уллыкка алучылар, опекуннар (химаячеләр), тәрбиягә алган ата-аналар да тапшырырга мөмкин булган башка документлар). | |
| | Гариза бирүче (гражданин), кабат мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте алу өчен түбәндәгеләрне күрсәтә:<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- шәхесне таныклаучы документлар (гражданлыксыз затлар өчен);<br>- ИПРИ (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен);<br>- хезмәт кенәгәсен (билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар өчен). | № 524н Федераль стандартның 16 п. 1 пунктчасы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 07.09.2012 ел, № 891 карары белән расланган Эшсез гражданнарны теркәү кагыйдәләренең 15 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| | Чит телдә төзелгән документлар рус теленә тәрҗемә ителергә тиеш. Тәрҗеменең дөреслеге һәм тәрҗемәче имзасының чынлыгы нотариуста расланган булырга тиеш.<br>2. Халык мәшгульлеге үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (эш бирүчегә) дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар булып, түбәндәгеләр тора:<br>- эш бирүченең кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышу дәүләт хезмәтен күрсәтү турында 26.02.2015 ел, № 125н Боерык белән расланган форма буенча гаризасы;<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданлыгына ия эш бирүчеләр – физик затлар өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар (чит ил гражданлыгына ия эш бирүчеләр – физик затлар өчен); | № 524н Федераль стандартның 5, 14 п. п.; |

| | | |
|---|---|---|
| | - шәхесне таныклаучы документлар (гражданлыксыз эш бирүчеләр – физик затлар өчен);<br>- 26.02.2015 ел, № 125н Боерык белән расланган форма буенча тутырылган “Хезмәткәрләргә ихтыяҗ, буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) булу турында мәгълүматлар” бланкы[22].<br>Гариза бирүче (эш бирүче), кабат шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшыра:<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданлыгына ия эш бирүчеләр – физик затлар өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар (чит ил гражданлыгына ия эш бирүчеләр – физик затлар өчен);<br>- шәхесне таныклаучы документлар (гражданлыксыз эш бирүчеләр – физик затлар өчен);<br>- Хезмәткәрләргә ихтыяҗ турындагы мәгълүматлар.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте | № 524н Федераль стандартның 22 п. 1 пунктчасы”; |

| | | |
|---|---|---|
| | алуга гариза бланкын халык мәшгульлеге үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон формасы халык мәшгульлеге үзәгенең рәсми сайтына, Татарстан Республикасы порталына урнаштырылган.<br>Гариза бирүчеләргә гариза бирү ысулын сайлап алу мөмкинлеге тәэмин ителә: халык мәшгульлеге үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать итеп, почта аша (электрон почтаны да кертеп), факсимиль элемтә ярдәмендә яки электрон рәвештә, шул исәптән Бердәм порталдан яки Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып яисә гаризаны КФҮ аша, ерактагы эш урыны аша тапшырып. | |

таблицаның 2.6 пунктының “Стандартка таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлектәге алтынчы, җиденче абзацлар белән тулыландырырга:

“Гариза бирүче тапшыруга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе бу Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучылар карамагында булган югарыда әйтелгән документларны гариза бирүчедән таләп итү тыела.”;

таблицаның 2.8 пунктының “Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт” графасының беренче, икенче абзацларын төшереп калдырырга;

таблицаның 2.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр күздә тотылмаган.<br>Халык мәшгульлеге үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (гражданинга) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булып, түбәндәгеләрнең булмавы тора:<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза;<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- гражданлыксыз затның шәхесен таныклаучы документлар (гражданлыксыз затлар өчен);<br>- ИПРИ (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен). | № 524н Федераль стандартның 5, 13 п. п.; |
| | Халык мәшгульлеге үзәгенә кабат мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (гражданинга) дәүләт хезмәте | № 524н Федераль стандартның 16 |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булып, түбәндәгеләрнең булмавы тора:<br>- гражданинның шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар (Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ; чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар; гражданлыксыз затның шәхесен таныклаучы документлар);<br>- ИПРИ (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен);<br>- хезмәт кенәгәсе (билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар өчен). | п. 1 пунктчасы; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 07.09.2012 ел, № 891 карары белән расланган Гражданнарны кулай эш эзләү максатыннан теркәү кагыйдәләренең 15 п.; |
| | Халык мәшгульлеге үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (эш бирүчегә) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булып, түбәндәгеләр тора:<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза булмау;<br>- Хезмәткәрләргә ихтыяҗ турында мәгълүматлар булмау;<br>- гражданинның шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы | № 524н Федераль стандартның 5, 14 п. п.; |

| | | |
|---|---|---|
| | документлар яки аларны алыштыручы документлар булмау (эш бирүче – физик зат өчен);<br>- гариза бирүче гаризасын эш бирүче – юридик зат яки шәхси эшкуар сыйфатында биргән очракта, эш бирүченең дәүләт теркәвенә алынуы турында Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрында мәгълүматлар булмау;<br>- рәсми мөрәҗәгатькә резидент булып тормаучы эш бирүче хакында чит ил юридик затларының аккредитация үткән филиалларының, вәкиллекләренең дәүләт реестрында чит ил юридик затының яисә вәкиллегенең аккредитация үтү фактын раслаучы мәгълүматлар булмау турында җавап алу.<br>Гариза бирүче (эш бирүче), кабат шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булып, түбәндәгеләрнең булмавы тора:<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданлыгына ия эш бирүчеләр – | 09.07.1999 ел, № 160-ФЗ Федераль законның 4 ст. 3 өл.;<br><br>№ 524н Федераль стандартның 22 п. 1 пунктчасы”; |

| | | |
|---|---|---|
| | физик затлар өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар (чит ил гражданлыгына ия эш бирүчеләр – физик затлар өчен);<br>- шәхесне таныклаучы документлар (гражданлыксыз эш бирүчеләр – физик затлар өчен);<br>- Хезмәткәрләргә ихтыяҗ турындагы мәгълүматлар.<br>Гражданинга кулай эш эзләүдә булышу дәүләт хезмәтен күрсәтүдән, ә эш бирүчегә яки аның вәкиленә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышу дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып, халык мәшгульлеге үзәгенә алкоголь, наркотик матдәләр яки миңгерәткеч матдәләр куллану аркасында барлыкка килгән исерек хәлдә мөрәҗәгать итү, ялган мәгълүмат яки дөрес булмаган белешмәләр тапшыру тора. | |

таблицаның 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына тәңгәл рәвештә, әлеге объектларның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү бүлмәләре аерым керү юлы ясалган биналарның түбәнге катларына яки аерым торучы биналарга урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыныннан инвалидларның тоткарлыксыз файдалана алуы (бүлмәләргә уңайлы рәвештә керү-чыгуы, алар эчендә хәрәкәт итүе) тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә керү һәм аннан чыгу урыннары автоном өзлексез ток чыганагы булган, тиешле күрсәткеч язулар белән җиһазландырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарында күренеп торган урынга янгын сүндерү чараларының урнашу һәм килүчеләрне һәм халык мәшгульлеге үзәге белгечләрен эвакуацияләү юллары схемасы куела.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыннары тавышлы мәгълүмат бирү һәм электрон хәбәр итү системалары белән | |

| | | |
|---|---|---|
| | җиһазландырыла. Хезмәт күрсәтү залларында (мәгълүмат залларында) белешмә-мәгълүмат һәм эзләү системалары булган, гражданнарга кулай эш вариантларын мөстәкыйль сайларга мөмкинлек бирүче исәпләү һәм электрон техника чаралары (ПЭВМ) куела. Белешмә-мәгълүмат һәм эзләү системалары белән эшләү кагыйдәләре, шулай ук халык мәшгульлеге үзәгенең исәпләү һәм электрон техника чараларының эшләве өчен җаваплы хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм урнашкан урыны турындагы белешмәләр ПЭВМ куелган урын белән янәшәдәге мәгълүмат стендына урнаштырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла һәм гаризалар бланклары, | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәткәрләргә ихтыяҗ бланклары, өләшеп бирелүче мәгълүмат материаллары белән тәэмин итеlә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарында җәмәгатьчелек файдалана ала торган урыннар (бәдрәфләр) һәм килүчеләрнең өс киемнәрен саклау урыннары булдыру күздә тотыла.<br>Халык мәшгульлеге үзәге белгеченең эш урыны сигнализация чаралары (стационар “хәвеф төймәләре” яки күчереп йөртелүче күпфункцияле брелок коммуникаторлар) белән җиһазландырыла, стенага эленгән, фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән мәгълүмат тактасы яки өстәл өстенә куелган табличка белән җиһазландырыла.<br>Халык мәшгульлеге үзәге белгече күкрәккә тагыла торган, фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән шәхси карточка (бейдж) белән тәэмин итеlә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урынга, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, куела.”; | |

таблицаның 2.15 пунктының “Стандартка таләпләрнең эчтәлеге” графасының беренче өлешен түбәндәге эчтәлектәге алтынчы абзац белән тулыландырырга:

“5. Инвалидларга аларның хезмәт күрсәтүләрне башка затлар белән бертигез алуына комачаулаучы киртәләрне узуда ярдәм күрсәтү.”;

3.6.1. пунктны “кабат” сүзеннән соң “шәхсән” сүзе белән тулыландырырга;

5.2 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;”;

Административ регламентның 7 нче кушымтасында түбәндәге эчтәлектәге позицияләрне:

| | | |
|---|---|---|
| “Әлмәт шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ” | (8553) 32-34-99 | 423452, Әлмәт ш., Герцен ур., 86а й. Czn.Almet@tatar.ru |
| “Югары Ослан районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84379) 2-17-57 | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 1 й. Czn.V-uslon@tatar.ru |
| “Биектау районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84365) 2-16-17 | 422700, Биектау ав., Үзәк ур., 7 й. CZN.VGora@tatar.ru |
| “Мөслим районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85556) 2-57-37 | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й. Czn.Muslymovo@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| “Мәскәү районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 543-47-72 | 420039, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. czn.moskovski@tatar.ru |
| “Яңа Савин районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 543-19-52 | 420044, Казан ш., Ибраһимов ур., 41 й. Czn.Novosavin@tatar.ru |

түбәндәге эчтәлектәге позицияләргә алмаштырырга:

| | | |
|---|---|---|
| “Әлмәт шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ” | (8553) 32-34-99 | 423452, Әлмәт ш., Герцен ур., 86а й. Czn.Almet@tatar.ru |
| “Югары Ослан районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84379) 2-18-99 | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 1 й. Czn.V-uslon@tatar.ru |
| “Биектау районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84365) 3-16-17 | 422700, Биектау ав., Үзәк ур., 7 й. CZN.VGora@tatar.ru |
| “Мөслим районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85556) 2-55-80 | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й. Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| “Мәскәү районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 564-58-72 | 420039, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. czn.moskovski@tatar.ru |
| “Яңа Савин районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 560-88-98 | 420044, Казан ш., Ибраһимов ур., 41 й. Czn.Novosavin@tatar.ru |

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**